# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 1** **09.12.2019 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге составына керүче Яңа Сәфәр, Горбуновка торак пунктларына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Яңа Сәфәр, Горбуновка торак пунктларында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Сәфәр, Горбуновка торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 (җиде йөз) сум күләмендә, көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Яңа Сәфәр, Горбуновка авыллары юлларын ремонтлау һәм карап тоту.
- Сабантуй бәйрәмнәрен үткәрү урыннарын төзекләндерү, электр җайланмасы белән тәэмин итү, бүләкләр сатып алу.
- Яңа Сәфәр, Горбуновка авылларында массакүләм чаралар үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, 23 февраль; 8 Март; юбилярларны котлау, спорт ярышлары уздыру өчен чыгымнар, ритуаль хезмәтләргә чыгымнар).
- Яңа Сәфәр, Горбуновка авылларына урам яктырткычлары сатып алу.
- Яңа Сәфәр, Горбуновка авыллары территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү.
- Яңа Сәфәр, Горбуновка авылларында аз керемле гаиләдәге балаларга ярдәм итү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Баек авылы, Совет урамы, 2 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Баек авыл җирлеге башлыгы** **Ф.М.Фахерлегаянов**